РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Буа шәһәре

22.10.2024 №286/Бк/к

Татарстан Республикасы Буа район Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының муниципаль бюджет мәдәният учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәне, түләүле хезмәтләр, түләүле хезмәтләргә тарифлар исемлеген һәм түләүле хезмәтләр күрсәткәндә ташламалар турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2014 елның 21 июлендәге 340-п номерлы карарына (19.04.2016 № 169-п, 20.06.2018 № 171-п, 10.03.2022 №52/Бк/к, 19.02.2024 №40/Бк/к номерлы карарлары редакциясендә) үзгәрешләр кертх хакында

Россия Федерациясенең «Мәдәният турында Россия Федерациясе законнары нигезләре» 1992 елның 9 октябрендәге 3612-1 номерлы Законы, Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының «Унсигез яшькә җитмәгән, шулай ук төп һөнәри белем бирү программалары буенча белем алучы затларның музейларга түләүсез керү тәртибен раслау турында» 2015 елның 17 декабрендәге 3119 номерлы боерыгы нигезендә, 2018 елның 22 сентябрендәге 2525 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсен үтәү йөзеннән һәм Буа муниципаль районы Муниципаль мәдәният учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтү процедурасын, шул исәптән түләүле хезмәтләр күрсәткәндә бәя кую тәртибен һәм шартларын тәртипкә китерү максатларында, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Буа район Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының муниципаль бюджет мәдәният учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәне, түләүле хезмәтләр, түләүле хезмәтләргә тарифлар исемлеген һәм түләүле хезмәтләр күрсәткәндә ташламалар турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2014 елның 21 июлендәге 340-п номерлы карарына (19.04.2016 № 169-п, 20.06.2018 № 171-п, 10.03.2022 №52/Бк/к, 19.02.2024 №40/Бк/к карарлары редакциясендә) (алга таба – карар), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 3 нче кушымта таблицасының 4 п. үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| № | Хезмәт күрсәтү исеме | Үлчәү берәмлеге | Хезмәт бәясе, сум |
|---|---|---|---|
| **4** | "Буа туган якны өйрәнү музее" МБУ хезмәтләре | | |
| 4.1 | Керү өчен түләү | | |
| - | Мәктәпкәчә яшьтәге балалар | 1 кеше | Түләүсез |
| - | Мәктәп укучылары | 1 кеше | 100 |
| - | Мәктәп укучылары һәм студентлар өчен Пушкин картасы буенча керү билеты | 1кеше | 100 |
| - | Студентлар | 1 кеше | 100 |
| - | Өлкәннәр ( РФ гражданнары ) Взрослые (Foreigner- чит ил гражданнары) | 1 кеше | 200 |
| 4.2 | Экскурсия хезмәте күрсәтү | | |
| - | Мәктәпкәчә яшьтәге балалар һәм 14 яшькә кадәрге мәктәп укучылары | 1 кеше | 100 |
| - | Мәктәп укучылары һәм студентлар өчен Пушкин картасы буенча керү билеты | 1 кеше | 200 |
| - | Башка категорияләр | 1 кеше | 400 |
| 4.3 | Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Күл Черкене авылындагы Б. Урманче музее буенча экскурсион хезмәт күрсәтү | 1 кеше | Түләүсез |
| 4.4 | Пушкин картасы буенча үткәрелә торган чаралар (мастер-классլар, квест-уен, иҗади очрашулар һ.б.) | 1 кеше | 300 |
| 4.5 | Туристларга хезмәт күрсәтү | | |
| - | Туристларны озата бару, шул исәптән Пушкин картасы буенча | 1 кеше | 200 |
| - | Туристларга шәһәр буйлап, шул исәптән Пушкин картасы буенча экскурсия | 1 кеше | 300 |
| - | Туристларга туристлык маршруты буенча, шул исәптән Пушкин картасы буенча экскурсия | 1 кеше | 500 |
| Ташламалар | | | |
| Ташламалар бирелә торган гражданнар категорияләре | | | Ташлама күләме, % |
| - Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары, хәрби | | | 100 |

| | |
|---|---|
| хәрәкәтләр инвалидлары, махсус хәрби операциядә ирекле һәм мобилизацияләнгәннәрне дә кертеп катнашучы (катнашкан) затлар * | |
| - I һәм II төркем инвалидлар, физик мөмкинлекләре чикләнгән кунакларны озата йөрүче затлар* | 100 |
| - инвалид балалар (бушлай йөрү хокукы бер озатучыга кагыла)* | 100 |
| - балалар йортларында һәм интернат-мәктәпләрдә булган ятим балалар*<br>-балалар, шулай ук ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган затлар (түләүсез керү хокукы бер озата йөрүчегә кагыла)* | 100 |
| - күпбалалы гаиләләр** | 100 |
| - махсус хәрби операциядә катнашучылар гаиләләре* | 100 |
| *Түләүсез керү өчен нигез ташламалы хезмәт күрсәтү башкарыла торган документлар тапшырудан гыйбарәт.<br>** РФ Хөкүмәтенең 2024 елның 29 июнендәге 1725-р номерлы күрсәтмәсе РФдә күпбалалы гаилә статусын раслый торган таныклыкның бердәм үрнәген һәм бердәм үрнәге бланкының( QR коды) тасвирламасын раслау турында | |

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://buinsk.tatarstan.ru. урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Н. Садретдиновага йөкләргә.

Җитәкче Л.Р. Шакирҗанов